Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

20.05.2021 Менделеевск ш. № 416

хуҗалык кенәгәсеннән өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 19 февралендәге 108 номерлы карары белән расланган хуҗалык кенәгәсеннән өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Административ регламентның 3.3.1. пунктында «яисә МФЦ аша» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. Административ регламентның 2.15 пунктындагы 12 абзацында «, МФЦда» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendelevsk.tatar.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.А.Абдуллин